СОВЕТ КЕМЕШ-КУЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.61, с. Кемеш-Куль,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422147

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӨМЕШ-КҮЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 61 нче йорт, Көмеш-Күл авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422147

тел.(факс): (85563) 2-46-38; e-mail: KemKul.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
№ 4-24 28.03. 2023ел

Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының
2020 елның 19 февралендәге 4-47 номерлы карарының
үз көчен югалтуын тану турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның $12^1$ статьясының $4^2$ өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советы

к а р а р к а б у л и т т е:

1. Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Советының 2020 елның 19 февралендәге «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 4-47 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы И.Н. Сәләхетдиновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Көмеш-Күл
авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе /И.Н.Сәләхетдинов/